**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«03» 06 2020 ел — Яр Чаллы — № 2099

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культураны һәм спортны үстерү» программасын раслау хакында» 2015 елның 11 декабрендәге 3491 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

COVID-19 коронавирусы пандемиясе һәм планлаштырылган чараларның саны киму белән бәйле рәвештә

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культураны һәм спортны үстерү» программасын раслау хакында» 2015 елның 11 декабрендәге 3491 номерлы карарына (2018 елның 12 январендагы 71 номерлы, 2019 елның 18 декабрендәге 5491 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесендә 2020 елга финанслау күләмен 145 659,00 сум күләмендә киметеп үзгәрешләр кертергә.
2. «2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культураны һәм спортны үстерү» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганагы» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләме | Программаны финанслауның гомуми күләме 2018-2020 елларда 4 667 586,36 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2018 елда – 1 477 922,20 сум;<br>2019 елда – 1 531 023,16 сум;<br>2020 елда – 1 658 641 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен |

| | |
|---|---|
| | төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чараларны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 03.06
2099 номерлы карарына кушымта

**«2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (сумнарда) | | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | Барлыгы | | |
| I. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча оештыру чаралары | | | | | | | |
| 1. | Муниципаль район җирлекләрендә халык тарафыннан суррогат куллануга юл куймау максатында ай саен алкогольле продукцияне сатуга мониторинг | | | | | финанслау таләп ителми | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 2. | Район территориясендә ялган алкогольле продукцияне ачыклау буенча системалы планлы тикшерүләр үткәрү | | | | | финанслау таләп ителми | Тукай муниципаль районы эчке эшләр бүлеге |
| 3. | Тәмәке тартуның зыяны һәм нәтиҗәләре турында күрсәтмә мәгълүмат урнаштыру | | | | | агымдагы финанслау | район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге |
| 4. | Балигъ булмаганнарга алкогольле продукция һәм сыра сату фактларын ачыклау, вакыт буенча алкоголь сатуны чикләү, шулай ук ике төрле билгеләнештәге спиртлы продукция сатуны чикләү буенча мобиль төркем эше | | | | | агымдагы финанслау | Тукай муниципаль районы эчке эшләр бүлеге, район Башкарма комитеты, алкоголь инспекциясенең территориаль бүлеге |
| 5. | Халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, шул исәптән алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке тартуның зыяны турында | | | | | агымдагы финанслау | "Татмедиа" АҖ филиалы "Якты юл" газетасы редакциясе |
| 6. | Муниципаль районның рәсми сайтында | | | | | финанслау таләп | Муниципаль |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | программаның иң мөһим чаралары турында мәгълүмат урнаштыру | | | | | ителми | район Башкарма комитеты |
| 7. | Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны тикшерү буенча рейдлар үткәрүне оештыру | | | | | финанслау таләп ителми | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия |
| 8. | Профилактика системасы хезмәтләре исәбендә торучы гаиләләрнең район банкын даими яңарту | | | | | финанслау таләп ителми | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия |
| II. Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар | | | | | | | |
| 9. | Җәйге каникул вакытында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру | | | | | агымдагы финанслау | "Тукай муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ, мәгариф идарәсе |
| 10. | Авыл җирлекләрендә нарколог психиатрның күчмә лекцияләре, темалар:<br>- алкоголь, сыра куллануны кисәтү;<br>- тәмәке тартуны һәм тарту катнашмаларын куллануны профилактикалау;<br>- яшүсмерләрнең суицидаль тотышын кисәтү;<br>- наркотикларга бәйлелек куркынычы факторларын кисәтү | | | | | агымдагы финанслау | "Тукай үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе Психиатр нарколог |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Акушер гинекологның планлаштырылган күчмә лекцияләре , темалар:<br>- яшүсмер кызлар арасында иртә йөклелекне кисәтү, гаилә кыйммәтләрен формалаштыру;<br>- хатын-кыз организмы турында;<br>- аналык муенчыгының яман шешен профилактикалау;<br>- күкрәк яман шешен профилактикалау | | | | | агымдагы финанслау | "Тукай үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе Акушер гинеколог |
| 12. | Инфекционистның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- ВИЧ инфекциясе һәм СПИД;<br>- куркынычсызлык-безнең сайлау | | | | | агымдагы финанслау | "Тукай үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе Инфекционист |
| 13. | Терапевтларның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- эчәклек яман шешен профилактикалау,<br>- йөрәк-кан тамырлары авыруларын профилактикалау | | | | | агымдагы финанслау | "Тукай үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе Терапевт |
| 14. | Ел саен 31 майда "Бөтендөнья тәмәке төтененнән башка көн" профилактик акциясен оештыру, тематик викториналар, конкурслар, иҗади эшләр күргәзмәләре үткәрү белән | | | | | агымдагы финанслау | Мәгариф идарәсе, мәдәният бүлеге |
| 15. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча массакүләм мәдәни чаралар уздыру | - | 5000 | 92000 | 97000 | "Мәдәният һәм ял үзәге" МБУ | Мәдәният бүлеге |
| 16. | Китапханәләрдә тәмәке тартуның, алкогольле продукция һәм сыра куллануның зыяны турында китап-иллюстратив күргәзмәләр оештыру | | | | | финанслау таләп ителми | Мәдәният бүлеге |
| 17. | Алкогольле продукция куллануны һәм социаль тискәре күренешләрне профилактикалау буенча түгәрәк өстәлләр, акцияләр үткәрү | 3000 | 0 | 13000 | 16000 | "Мәдәният һәм ял үзәге" МБУ | Мәдәният бүлеге |
| 18. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча, ата-аналар ягыннан балаларга контрольне көчәйтү | | | | | финанслау таләп ителми | Мәгариф идарәсе |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | турында ата-аналар җыелышлары үткәрү | | | | | | |
| 19. | Балалар һәм яшүсмерләрдә зарарлы гадәтләрне профилактикалау буенча укучылар һәм аларның әти-әниләре арасында, табиб-педиатрлар, психиатрлар, наркологлар, полиция хезмәткәрләре җәлеп итеп, лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү | | | | | финанслау таләп ителми | Мәгариф идарәсе, "Тукай муниципаль районы үзәк хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе |
| 20. | Төрле яшьтәге халык катнашында аларның яшәү урыны буенча физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чаралары үткәрү | 421143 | 540192,56 | 275484 | 1236819,56 | "Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы" МБУ- 2018, 2019, 2020 Тукай муниципаль районының “Спорт мәктәбе МБУ - 2020 | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 21. | Районның белем бирү учреждениеләре, авыл җирлекләре арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм эшен иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү | 123000 | 132513,84 | 123000 | 378513,84 | "Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы" МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 22. | Спорт корылмаларының, балаларның һәм яшүсмерләрнең яшәү урыны буенча клубларның даими эшен, өстәмә белем алу белән мәшгульлекне тәэмин итү | | | | | агымдагы финанслау | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 23. | Район мәгариф учреждениеләре спорт секцияләре һәм түгәрәкләре эшен оештыру, аларның матди базасын ныгыту | 221000 | 80000 | 221000 | 522000 | "Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы" МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24. | Яшәү урыны буенча "куркыныч төркем" балалары һәм яшүсмерләре белән эшне оештыру | | | | | агымдагы финанслау | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 25. | Спорт төрләре буенча ТР, РФ беренчелегендә һәм чемпионатында катнашу (яшәү, туклану, йөрү чыгымнары) | 593229,20 | 551368 | 685157 | 1829754,20 | "Тукай муниципаль районы яшүсмерләр клубы" МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 26. | Даими рәвештә алкогольле продукцияне кулланучы мәшгуль булмаган гражданнар белән шәхси эш алып бару, аларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү | | | | | агымдагы финанслау | "Тукай муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ, мәгариф идарәсе |
| 27. | "Безопасное колесо" уены | 15000 | 0 | 15000 | 30000 | "Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе | Мәгариф идарәсе |
| 28. | Татарстан Республикасы укучылары арасында спорт туризмы төрләре буенча республика ярышларының муниципаль этабы | 8000 | 8000 | 8000 | 24000 | "Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе | Мәгариф идарәсе |
| 29. | "Ватанга хезмәт итәргә әзерләнәбез!" мәктәп укучылары арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча ачык ярышлар | 8000 | 0 | 8000 | 16000 | "Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе | Мәгариф идарәсе |
| 30. | Белем бирү оешмалары укучылары арасында иң | 0000 | 0 | 40000 | 40000 | "Тукай | Мәгариф |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яхшы физик әзерлек конкурсы | | | | | муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе | идарәсе |
| 31. | "Бөтен гаилә белән стартка!" әти-әниләр катнашында спрорт бәйрәме | 15000 | 15000 | 15000 | 45000 | "Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе | Мәгариф идарәсе |
| 32. | ТР мәктәп укучылары спартакиадасы һәм спорт туризмы кысаларында мәктәп укучылары арасында үткәрелгән республика ярышларында катнашу | 59550 | 157948,76 | 132000 | 349498,76 | "Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе | Мәгариф идарәсе |
| 33. | "Кышкы әкият" кар сыннары район конкурсы | 11000 | 31000 | 31000 | 73000 | "Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе | Мәгариф идарәсе |
| 34. | Спорт төрләре буенча мәгариф хезмәткәрләре спартакиадасы | 0 | 10000 | 0 | 10000 | Мәгариф идарәсе | Мәгариф идарәсе |
| | Барлыгы | 1 477 922,20 | 1 531 023,16 | 1 658 641 | 4 667 586,36 | | |